**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2022 елның 28 гыйнвары № 5 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 октябрендәге 1844 номерлы «Тикшерү рәвешләрен эшләүгә, аларның эчтәлегенә, тикшерү кәгазьләре формалары проектларын иҗтимагый тикшерүгә, раслауга, куллануга, тикшерү кәгазьләре формаларын актуальләштерүгә, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларына таләпләрне раслау турында» Карары, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 ел, № 81 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлегенең) беркетелгән формасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасының
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының № 5
2022 елның 28 гыйнвары
карарына кушымта

### Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасы

__________________ «___» __________ 20 ___ ел
(планлы тикшерүне үткәрү урыны) (кәгазьне тутыру датасы)

"___" сәгать «___" минут
(кәгазьне тутыру вакыты)

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында файдаланыла торган
тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

___________________________________________________________________________
тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

_____________________________________________________________________ нигезендә
(тикшерү кәгазе формасын раслау турында хокукый акт реквизитлары)

_________________________________________________________________нигезендә
(планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә реквизитлары)

Тикшерү учет номеры: ______________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(планлы тикшерү номеры һәм «Бердәм тикшерүләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәп номерын бирү датасы)

Тикшерүне уздырган вазыйфаи затлар: _____________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(тикшерү уздыручы вазыйфаи затларның вазыйфалары, фамилияләре һәм инициаллары)

Тикшерелә торган субъект:
_________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(юридик затның, шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булган очракта)

___________________________________________________________________________
(юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлеге төре, җитештерү объекты, тибы, характеристикасы, риск категориясе, куркынычлык классы)

Адрес: _____________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны һәм (яисә) юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган объектларны күрсәтү)

Чикләүләр: _______________________________________________________________________
_______________________________________________________________
(планлы тикшерү предметын Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясе субъекты законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр белән чикләүне күрсәтү)

Тикшерү предметын тәшкил иткән юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен яки үтәлмәвен раслый торган мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар исемлеге:

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Алар тарафыннан мәҗбүри таләпләр куелган структур берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларның реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Кулланыла алмый | Искәрмә |
| 1. | Җир кишәрлеген тикшерелә торган юридик зат яисә индивидуаль эшкуар билгеләнгән максатчан билгеләнеш һәм (яисә) рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә кулланамы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 7 статьясындагы 2 пункты, 42 статьясы | | | | |
| 2. | Тикшерелә торган юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләре, җир кишәрлекләренең өлешләренә) Россия Федерациясе законнарында каралган хокуклары  бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 3. | «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләрегенә, җир кишәрлегенең бер өлешенә) хокуклар теркәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 26 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Граждан кодексының 8.1 статьясы | | | | |
| 4. | Тикшерелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан файдаланылган җир кишәрлегенең мәйданы хокук билгели торган документларда күрсәтелгән мәйданга туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 5. | Тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган җир | Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясындагы 3 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кишәрлеге чикләренең борылыш нокталары нигезләмәсе, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең нокталары урнашуы турындагы белешмәләргә туры киләме? | пункты, 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 6. | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) файдалану җирләрне яисә җир кишәрлекләрен файдалануга рөхсәт нигезендә мондый җирләр яисә җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга китерсә, җир яисә җир кишәрлекләре рөхсәт ителгән файдалану өчен яраклы хәлгә китерелгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.35 статьясындагы 1 пунктчасы | | | | |
| 7. | Сервитутның тәэсире туктатылган очракта, тикшерелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр алар мөнәсәбәтендә сервитут билгеләнгән очракта, җир кишәрлеген куллану өчен яраклы халәткә китерү бурычы рөхсәт ителгән куллану нигезендә башкарыламы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.25 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасы | | | | |
| 8. | Тикшерелүче юридик зат (дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт һәм муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном), казна предприятиесе, Россия Федерациясе Президентының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәгеннән тыш) җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) даими (сроксыз) файдалану хокукын | «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | яңадан рәсмиләштерү яисә җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) милеккә сатып алу хокукын яңадан рәсмиләштерү бурычы үтәлгәнме? | | | | | |
| 9. | Җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән срокларда файдаланунының (үзләштерүнең) мәҗбүрилеге турындагы таләп үтәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 маддәсе, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 284 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 45 статьясы 2 пункты, «Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре турында» 66-ФЗ номерлы 1998 елның 15 апрелендәге Федераль законының 19 статьясы 2 өлешенең 7 пункты. | | | | |

Исемлектәге сораулар буенча аңлатмалар һәм өстәмәләр:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Тикшерү уздыручы затның (затларның) имзалары:
____________________________________________________________________________
(Вазыйфасы, Ф.И.А.и.)
____________________________________________________________________________
(Вазыйфасы, Ф.И.А.и.)

Тикшерү кәгазе белән таныштым (а)__________________________________________________
____________________________________________________________________________
җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр
аның вәкаләтле вәкиле) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

"___" ____________ 20_____ ел ________________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазьләре белән танышудан баш тарту турында билге:

______________________________________________________________________________

(тикшерү уздыручы затның , вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

"___" ____________ 20_____ ел ________________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазенең күчермәсен алды_________________________________________________

______________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле вазыйфасында)

"___" ____________ 20_____ ел ________________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазен алудан баш тарту турында тамга: ________________________________________

______________________________________________________________________________

(тикшерү уздыручы затның , вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

"___" ____________ 20_____ ел ________________________________________________

(имза)